КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 9 декабрь г.Казань № 1116

«Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә һәм Татарстан Республикасы Лаеш, Питрәч, Биектау һәм Зеленодольск муниципаль районнарының «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләреннән 3 км ераклыкта урнашкан территорияләрендә атмосфера һавасына антропоген йөкләнешне киметү чараларын гамәлгә ашыру турында

«Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы, «Атмосфера һавасын саклау турында» 1999 елның 4 маендагы 96-ФЗ номерлы, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә, шулай ук Казан шәһәренең актив үсеше шартларында экологик иминлекне тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә һәм Татарстан Республикасы Лаеш, Питрәч, Биектау һәм Зеленодольск муниципаль районнарының «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләреннән 3 км ераклыкта урнашкан территорияләрендә Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына объектларны төзүне һәм (яисә) реконструкцияләүне планлаштыручы юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар тарафыннан I, II һәм III категорияләр объектларына кертү критерийларына туры килә торган мәгълүматлар исемлеген расларга (алга таба - хуҗалык итүче субъектлар).

27. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы.

әлеге карарның 1 пункты нигезендә хуҗалык итүче субъектлар тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрне җыюны һәм гомумиләштерүне тәэмин итәргә;

әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә дәүләт программаларын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар

министрлыгы заказы буенча төзелгән атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр чыгаруларның стационар һәм күчмә чыганаклары турында белешмәләрнең җыелма базасы (алга таба - мәгълүматларның җыелма базасы) нигезендә әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән күрсәткечләр кергән көннән алып 20 эш көненнән дә артык булмаган чорда «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә һәм Татарстан Республикасы Лаеш, Питрәч, Биектау һәм Зеленодольск муниципаль районнарының «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләреннән 3 км ераклыкта урнашкан территорияләрендә атмосфера һавасына тискәре йогынты ясый торган гамәлдәге производстволар киңәйтелгәндә яисә яңа производстволар булдырганда атмосфера һавасында пычраткыч матдәләрнең рөхсәт ителә торган күләменнән артып китүләре булмау предметына атмосфера һавасының сыйфатын анализлауны башкарырга;

әлеге пунктның өченче абзацы нигезендә үткәрелгән анализ нәтиҗәләре буенча күрсәтелгән анализ нәтиҗәләрен җиде эш көненнән дә артык булмаган вакытта Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенә, Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Идел-Кама төбәкара идарәсенә, «Төзелеш һәм архитектура буенча Татарстан Республикасы дәүләт экспертизасы һәм бәяләр билгеләү идарәсе» дәүләт автоном учреждениесенә, шулай ук Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән күрсәткечләрне тапшырган хуҗалык субъектлары адресына җибәрергә;

II категория объектларында хуҗалык һәм (яисә) башка эшчәнлекне гамәлгә ашыручы хуҗалык субъектлары тарафыннан бирелә торган әйләнә-тирә мохиткә йогынты турында декларацияләр материалларын караганда әлеге пунктның өченче абзацы нигезендә үткәрелгән анализ нәтиҗәләрен, шулай ук җитештерү экология контролен оештыру һәм гамәлгә ашыру нәтиҗәләре турында хисапларны исәпкә алырга.

3. Әлеге карарның 2 пунктындагы өченче абзацын гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында хуҗалык итүче субъектларга Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән күрсәткечләрне тапшырырга тәкъдим итәргә.

4. Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенә хуҗалык итүсе субъектларга уңай санитар-эпидемиологик бәяләмәләр биргәндә, Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Идел-Кама төбәкара идарәсенә хуҗалык субъектларына комплекслы экологик рөхсәтләр биргәндә, II категорияле объектларда хуҗалык һәм (яисә) башка эшчәнлекне гамәлгә ашыручы хуҗалык итү субъектлары тарафыннан бирелә торган декларацияләр материалларын, шулай ук җитештерү экология контролен оештыру һәм гамәлгә ашыру нәтиҗәләре турында хисапларны караганда, «Төзелеш һәм архитектура буенча Татарстан Республикасы дәүләт экспертизасы һәм бәя бирү идарәсе» дәүләт автоном учреждениесенә «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә һәм Татарстан Республикасы Лаеш, Питрәч, Биектау һәм Зеленодольск муниципаль районнарының «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләреннән 3 км ераклыкта

урнашкан территорияләрендә атмосфера һавасына тискәре йогынты ясый торган гамәлдәге производстволарны киңәйтүне яисә яңа производстволар төзүне күздә тоткан проект материалларын караганда әлеге карарның 2 пунктының өченче абзацы нигезендә уздырылган анализ нәтиҗәләрен законнарда беркетелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда исәпкә алырга тәкъдим итәргә.

5. Ел саен Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан оештырыла торган белешмәләрнең җыелма базасын актуальләштерүне исәпкә алып, әлеге карарның 2 пунктының өченче абзацы нигезендә үткәрелгән анализ нәтиҗәләренең гамәлдә булу срогы мондый анализны уздыру тәмамланган көннән алып 12 айдан да артык булмый билгеләргә.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 9 декабрь, 1116 нчы карары белән расланды

«Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә һәм Татарстан Республикасы Лаеш, Питрәч, Биектау һәм Зеленодольск муниципаль районнарының «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләреннән 3 км ераклыкта урнашкан территорияләрендә Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына объектларны төзүне һәм (яисә) реконструкцияләүне планлаштыручы юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар тарафыннан I, II һәм III категорияләр объектларына кертү критерийларына туры килә торган мәгълүматлар исемлеге

1. Атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр чыгарып ташлауларның мөмкин нормативлары проекты (булган очракта).

2. «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә һәм Татарстан Республикасы Лаеш, Питрәч, Биектау һәм Зеленодольск муниципаль районнарының «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләреннән 3 км ераклыкта урнашкан территорияләрендә объектларны төзүне һәм (яисә) реконструкцияләүне планлаштыручы юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар тарафыннан I, II һәм III категорияләр объектларына кертү критерийларына туры килә торган чыгарып ташлауларның рөхсәт ителгән нормативларының гамәлдәге проекты булмаганда «Атмосфера һавасын саклау турында» 1999 елның 4 маендагы 96-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясы, Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Атмосфера һавасына стационар чыганакларны һәм пычраткыч матдәләр чыгарып ташлауларны инвентарьлаштыру үткәрү, аның мәгълүматларын корректировкалау, мондый инвентаризация уздыру һәм корректировкалау нәтиҗәсендә алынган мәгълүматларны документлаштыру һәм саклау тәртибен раслау турында» 2021 елның 19 ноябрендәге 871 номерлы боерыгы белән расланган Атмосфера һавасына стационар чыганакларны һәм пычраткыч матдәләр чыгарып ташлауларны инвентарьлаштыру үткәрү, аның мәгълүматларын корректировкалау, мондый инвентаризация уздыру һәм корректировкалау нәтиҗәсендә алынган мәгълүматларны документлаштыру һәм саклау тәртибе таләпләре нигезендә башкарылган һавага чыгарулар һәм пычраткыч матдәләрне һавага чыгарулар чыганакларын инвентарьлаштыруның актуаль материаллары тапшырыла, атмосфера һавасына стационар чыганакларны һәм пычраткыч матдәләр чыгарып ташлауларны инвентарьлаштыру нәтиҗәләре турында хисапны да кертеп, шул исәптән:

объектта эшчәнлек төрләрен кыскача тасвирлау, файдаланыла торган чималның, ягулык-энергетика ресурсларының, материалларның исемлеге һәм кыскача характеристикасы; җитештерелә торган продукциянең проект һәм факттагы төрләре һәм күләмнәре, эшләр башкару һәм (яисә) хезмәтләр күрсәтү, шул исәптән тулаем чыгарулар исәпләнгән төп эшчәнлек күрсәткечләре; ташлауларның төп

технологик процесслары (булган очракта), җиһазлары һәм башка чыганаклары тасвирламасы, шулай ук газ чистарту җиһазларының саны, характеристикалары һәм нәтиҗәлелеге турында һәм һавага чыгаруларны элек үткәрелгән инвентарьлаштыру чорында гамәлгә ашырылган атмосфера һавасын саклау чаралары турында белешмәләр;

картографик материаллар (объектларның һәм атмосфераны пычрату чыганакларының пространствода урнашуын характерлый торган ситуацион план һәм карта-схема);

ташлауларның сыйфат һәм микъдар составын билгеләү исәпләре һәм нәтиҗәләре;

һавага чыгаруларның һәм атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр чыгаруларның чыганакларын инвентаризацияләгәндә кулланылган исәп-хисап программаларының экспорт файллары.

3. Түбәндәге проект документациясе белешмәләре:

атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр чыгарып ташлауларның параметрлары һәм аларның чыганаклары буенча күрсәткечләр;

атмосфераны пычрату чыганаклары буларак яңа төзелә торган объектларга кыскача характеристика;

картографик материаллар (проектлана торган объектларның һәм атмосфераны пычрату чыганакларының пространствода урнашуын характерлый торган ситуацион план һәм карта-схема);

атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр чыгару күрсәткечләрен исәпләү;

перспективалы үсешне исәпкә алып, атмосфера һавасындагы чыгарылмаларны таркату исәпләре;

эшләүләре атмосфера һавасын пычратуга төп өлеш кертәчәк чыганаклар исемлеге;

чыгарып ташлауларның мөмкин нормативлары (вакытлыча рөхсәт ителгән ташлаулар) буенча тәкъдимнәр;

проект документациясен әзерләгәндә кулланылган исәп-хисап программаларының экспорт файллары;

яңа һәм (яисә) реконструкцияләнә торган объектларны файдалануга тапшыру сроклары.

______________________